# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«31» 03 2021 ел ЯрЧаллы № 983

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 маендагы «Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 1802 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын актуальләштерү максатында, «Хокукка сәләтсез яисә өлешчә хокукка сәләтсез балигъ булганнарга опекун яисә попечитель булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу, исәпкә алу һәм әзерләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 30 декабрендәге 2361 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 елның 6 августындагы 3794 номерлы район Башкарма комитеты карарына таянып

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 маендагы 1802 номерлы карары белән расланган Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә чикләнгән күләмдә хокукка сәләтсез дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек булдыру һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (2 кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гариза (2 кушымта);

2. Эш урыныннан вазыйфасы һәм соңгы 12 ай өчен уртача хезмәт хакы күләме күрсәтелгән белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен - керемнәрне раслаучы башка документ (пенсионерлар өчен - пенсия таныклыгының күчермәсе) (алар бирелгән көннән соң бер ел дәвамында кабул ителә);

3. Опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданны таныклау нәтиҗәләре буенча сәламәтлек торышы турында медицина бәяләмәсе (бирелгән көннән алып өч ай эчендә кабул ителә);

4. Опекунның балигъ булган опекага алынучы белән бергә яшәвенә опекун булырга теләк белдергән гражданның гаилә әгъзаларының, 10 яшькә җиткән балаларның фикерен исәпкә алып, язма ризалыгы (опекун тарафыннан балигъ булган опекага алынучының опекун гаиләсе белән бергә яшәве турында карар кабул ителгән очракта);

5. Опекун булырга теләк белдергән гражданның әлеге Кагыйдәләрдә (булган очракта) билгеләнгән тәртиптә әзерләнүе турында документ;

6. Тәрҗемәи хәл.

Балигъ булганнарның опекун яисә попечитель булырга теләк белдергән, аның белән опекун итеп билгеләү турында гариза биргән көнгә кимендә 10 ел бергә яшәгән ата-аналары, әбиләре, бабайлары, абыйлары, апалары, балалары һәм оныклары (алга таба - опекун булырга теләк белдергән якын туганнары) яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына түбәндәге документларны тапшыра:

1. Гариза (2 кушымта).

2. Балигъ опекага алынучы белән туганлыкны раслаучы документлар».

1.2. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге» графасының 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1. Мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр яки торак урыныннан файдалану хокукын яисә торак урынга милек хокукын раслаучы документ, опекун булырга теләк белдергән гражданның яшәү урыныннан финанс шәхси счеты күчермәсе;

2. Опекун булырга теләк белдергән гражданның эчке эшләр органнары тарафыннан бирелгән гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә аңлы рәвештә җинаять кылган өчен хөкем ителгән булмавы турында белешмә;

3. Торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан бирелә торган белешмә;

4. Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнары яисә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнар тарафыннан бирелә торган пенсия алуны раслаучы белешмә - опекун булырга теләк белдергән граждан пенсионер булганда;

5. Никах турында таныклык күчермәсе (әгәр опекун булырга теләк белдергән якын туганы никахта торса).

6. Әгәр опека яки попечительлек балигълыкка ирешүгә бәйле рәвештә билгеләнсә, опекун булырга теләк белдергән якын туганының балигъ булган опекага алынучы белән, ул 18 яшькә җиткәнче, тиешле булмаган мөрәҗәгать фактлары булмау турында опека һәм попечительлек органнары бәяләмәсе.

Опека һәм попечительлек органының күрсәтелгән белешмәләре булган очракта ведомствоара запрос җибәрелми».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatrstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин